# Мәкальләрнең мәгънәсен аңлатыгыз:

- Яхшылык итсәң, үзеңә кайтыр.
- Изгелек эшләүнең иртәсе-киче юк.



Сүзләрне төзелеше ягыннан тикшер:

- ***Яхшылык, изгелек, кайтыр.***

Дәреснең темасы:

# ***Тамыр һәм кушымчалар.***

# Бу сүзләрнең кайсы кисәкләре уртак?

***Эшлә, эшче, эшлекле,***
***белә, белемле, белгеч, белдекле,***
***күңелле, күңелсез, күңелләр.***

***эш-лә, эш-че, эш-лек-ле,***
***бел-ә, бел-ем-ле, бел-геч, бел-дек- ле,***
***күңел-ле, күңел-сез, күңел-ләр***

**Тамыр – сүзнең төп лексик мәгънәсен белдерүче кисәк.**

# *Эш, бел, күңел*

сүзләре белән җөмләләр уйлагыз.

**Тамыр – сүзнең ваграк мәгънәле кисәкләргә бүленми торган өлеше.**

**Ул сөйләмдә үзе генә кулланыла  ала.**

# Бу сүзләрнең кайсы кисәге уртак?

Авылдаш, яшьтәш, классташ, партадаш, чордаш; каенлык, аланлык, җиләклек; ашла, эшлә, башла, барла; күңелсез, эшсез, уйсыз.

# Бер сүз белән әйт.

| | |
|---|---|
| Бер класста укучы балалар | классташлар. |
| Бер авылда яшәүче кешеләр | авылдашлар. |
| Калфак чигү остасы | калфакчы |
| Футбол, хоккей уйнаганда капка алдында сакта торучы кеше | капкачы. |
| Капчык күтәргән кеше | капчыклы. |
| Тел мәсьәләрен тикшерүче белгеч | телче. |
| Ике яки берничә төре булган әйбер | төрле. |
| Нинди булса да эш белән шөгыльләнергә кушу | эшлә. |
| Инсафлы, тыйнак кеше | әдәпле |
| Кешегә булыша, ярдәм итә торган кеше | ярдәмчел |
| Шат булу | шатлану. |

Сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртүче кушымчалар – сүз ясагыч кушымчалар дип атала һәм язуда /\ билгеләнә. Рус телендә приставка, суффикс, окончание төшенчәсе бар, татар телендә кушымчалар гына кулланыла.

# Кушымчалар өстәп языгыз:

Мин иртән торды... м һәм тәрәзә... гә
карады... м . Урам... да кар яуган. Бала... лар
кар тәгәрәтеп уйный... лар . Минем дә
уйныйсы... м кил... де . Мин киенде... м дә
алар янына чыкты... м .

**Сүз төзелеше** - сүзнең мәгънәле кисәкләрен-тамырын,нигезен, һәм кушымчаларны өйрәнә.

**Тамыр** - сүзнең ваграк мәгънәле кисәкләргә бүленми торган өлеше. Ул сүзнең төп лексик мәгънәсен белдерә, сөйләмдә үзе генә дә кулланыла.

**Кушымчалар** сүзнең лексик мәгънәсен яки формасын үзгәртә, үзләре генә кулланылмый.

1.Сүзнең мәгънәле кисәкләрен нинди фән өйрәнә?

а) сүзнең төзелеше һәм ясалышы дигән фән;

2.Мәгънәле кисәкләр ул...(дөрес булмаган җавапны тап):

) иҗек;

3.Тамыр ул...(дөрес булмаган җавапны билгелә:

г) Кем? Нәрсә? Сорауларына җавап бирүче кисәк.

4. Сүзнең мәгънәле кисәкләре дөрес билгеләнгән сүзне әйт:

)күңел-сез-лек-ләр-ем;

5.Җырлагансыз сүзе ничә мәгънәле кисәктән тора?

г)дүрт